РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

улица К.Маркса, дом 46,
город Чистополь, 422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

К.Маркс урамы, 46 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел.(84342) 5-13-38, тел/факс 5-13-38, E-mail: chistay@tatar.ru

***Постановление*** ***Карар***

07.03.2023 **г.Чистополь** №30

Һәр гаилә әгъзасына, яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган һәм 2023 елга салым салынырга тиешле керемнең чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 49,51 статьясы нигезендә «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында»гы 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә һәм Гаиләнең һәр әгъзасына, яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы нигезендә, шулай ук «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлегенең» коммерциячел булмаган партнерлыгының 2023 елның 31 гыйнварындагы 18 номерлы хатына таянып, Чистай шәһәр Башкарма комитеты,

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2023 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында Карар кабул итү өчен чик күрсәткечләрен билгеләү:

1.1. Гаилә әгъзалары милкендә булган һәм гаиләнең һәр әгъзасына салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме – 738 630 сум.

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме – 17 976 сум.

2. Чистай шәһәр Башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенең баш белгече гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип таныганда әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән күрсәткечләрдән файдаланырга тиеш.

3. Чистай шәһәр Башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенең баш белгече Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) әлеге карарны урнаштыруны тәэмин итәргә һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Шәһәр Башкарма
комитеты җитәкчесе И.Ф.Рәхимов